Чыганак: Совет Татарстаны композиторлары / төз. З. Хәйруллина; русчадан тәрҗ. Г. Зайнашева.- Казан: Таткнигоиздат, 1957.- Б. 143.



## АЛЕКСАНДР СЕРГЕЕВИЧ КЛЮЧАРЕВ

Александр Сергеевич Ключарев татар музыкасын үстерү өлкәсендә озак еллар уңышлы эшләгән талантлы рус композиторларының берсе. Үзенчәлекле иҗаты белән һәм татар музыкаль фольклорын җыеп эшкәртү, бастырып чыгару эшендә күрсәткән күп еллык хезмәте белән ул татар музыка культурасы үсешенә үзенең әһәмиятле өлешен кертте.

Ключаревның инде иҗат юлы утыз елдан артык чорны эченә ала. Шушы чор эчендә ул төрле жанрдагы, төрле формадагы музыкаль әсәрләр тудырды, бик күп халык көйләрен эшкәртте, җырлар, симфонияләр һәм балет язды. Композиторның симфоник музыка һәм татар совет җырларын тудыру өлкәсендәге хезмәте аеруча әһәмиятле. Аның музыкасы үзенең чын күңелдән язылган җылы лирикасы, юморы, дәртлелеге белән игътибарны җәлеп итә. Үзенчәлекле мелодияле, нечкә гармоник эшкәртүләргә, оркестрның матур яңгырашлы сурәтләүләренә бай музыкасы белән Ключарев Татарстан республикасында гына популярлашып калмыйча, илебезнең башка өлкәләрендә дә киң масса тыңлаучыларга якын таныш.

Александр Сергеевич Ключарев 1906 елның 19 февралендә Казанда туа. Музыка буенча башлангыч белемне Оренбург (хәзерге Чкалов) шәһәрендә ала. Оренбургта шул чорда танылган виолончелист профессор С. М. Козолупов һәм фортепиано укытучысы Н. Н. Козолуповалар, әле сабый бала гына булган Ключаревның музыкага сәләтен күреп, зур игътибар бирәләр.

1922 елны фортепианода искиткеч яхшы уйнаучы уналты яшьлек яшь егет Оренбург кинотеатрына пианист-иллюстратор булып эшкә керә. Биредә ул тавышсыз кинокартиналарга музыка уйный.

1924 елны Ключарев Казан музыка техникумына укырга керә һәм уку белән бергә профессиональ музыкант булып эшләвен дәвам итә. 1926—28 елларда ул Казан театр техникумының музыка бүлегендә мөдир була. Театр техникумын тәмамлаучы студентлар Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар», Гадел Кутуйның «Директор Җәмилев» исемле әсәрләрен куялар. Ключарев бу спектакльләргә музыкаль оформлениеләр яза. Аның музыкаль иҗатының беренче адымнары шушы әсәрләр белән бәйләнгән. Бу яшь артистлар труппасы белән Ключарев Урал һәм Себер буенча озак гастрольләрдә йөри.

Спектакльләргә музыкаль оформлениеләр язу белән бергә, Александр Сергеевич башка жанрларда музыка иҗат итүдә үзенең көчен сынап карый. 1926 елны кыллы квартет өчен «Җырлыйммы?» дигән пьеса яза. Берничә ел үткәннән соң, Вильом исемендәге квартет, бу пьесаның йөз тапкыр башкарылуына багышлап, авторга котлау телеграммасы җибәрә.

Башлап язучы композиторның шушы хезмәтендә инде якты бер колорит билгеләргә мөмкин була. Бу пьесада соңра композиторның бөтен иҗатына типик булган үзенчәлекләр — көйнең нәфислеге, сафлыгы, бик табигый агылуы, ачыклыгы, гармоник теленең үзенә бертөрле матур булуы күренә.

Александр Сергеевич Ключаревның иҗат үсешендә татар музыка культурасының яшь эшлеклеләре С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, Ф. Туишев, Г. Сөләйманова, З. Хәбибуллиннар белән очрашулар зур роль уйный. Бу очрашулар соңга таба күпьеллык иҗат дуслыгына, чын дуслыкка әверелә. Яшь музыка эшлеклеләре үзара иҗади бәйләнештә яшәп, татар профессиональ музыкасын үстерүгә бергәләп хезмәт итәләр.

Музыка техникумында теоретик белем алу, башкаручы-музыкант буларак татар халкының танылган талантлы музыкантлары, җырчылары белән бергә күп еллар эшләү, халык көйләрен өйрәнү һәм, ниһаять, үзенең композиторлык сәләтен сынап карап беренче язган тәҗрибәләре — болар барысы бергә яшь музыкантка ныклап инде чын иҗат юлына керергә әзерлек була.

Музыкаль белемен тагын да арттыру һәм композиторлык сәләтен үстерү өчен, Ключарев 1928 елны Москва дәүләт консерваториясенә керә һәм 1933 елга кадәр композиция классында укый.

Ул, совет музыкасының күренекле мастерлары — профессорлар: Н. С. Җиляев, Р. М. Глиэр классында укып, бай иҗади сәләтен музыкаль белем белән бәйли һәм композиторлык осталыгының нигезләрен үзләштерә. Консерваториядә укыган чагында яшь музыкант һәрвакыт практик эш күрсәтергә, иҗат итәргә омтыла. Москвада татар драма театрының музыка бүлегендә биш ел мөдир булып эшли. Шул дәвер эчендә егермедән артык спектакльгә музыкаль оформление яза. Шулар арасыннан «Галиябану» (М. Фәйзи), «Зәңгәр шәл», «Ил» (К. Тинчурин) спектакльләренә язган музыкалары игътибарга лаеклы була.

Театраль музыка өлкәсендәге иҗат эшчәнлеге композиторга музыкаль фикер йөртүен, музыкаль образлар тудыру сәләтен үстерергә ярдәм итә. Бу елларны спектакльләргә язган җырларыннан һәм инструменталь әсәрләреннән бик күбесе халыкка тиз тарала һәм озак гомерле әсәрләр булып кала. Мәсәлән: «Зәңгәр шәл» спектакленә язылган Мәйсәрә җыры, лирика белән сугарылган моңлы көй, хәзер дә халыкның иң яраткан җыры булып санала һәм Татарстанның күп кенә районнарында аны татар халык көе дип йөриләр. «Галиябану» симфоник сюитасы да (шул исемдәге драмага нигезләнеп язылган) — киң тыңлаучыларга танылган әсәр.

1934 елны Александр Сергеевич Ключарев Москвадан Уфага килә һәм Башкорт фәнни-тикшеренү институтының фольклор секторында мөдир һәм башкорт радиокомитетында музыка редакторы булып эшли.

Халык көйләрен чын күңелдән яратучы композитор Ключарев башкорт фольклорын бик бирелеп өйрәнә, бирегә төзелеше белән башкорт музыкасына якын торган татар музыкасын белүе аңа зур ярдәм итә.

Уфада Ключарев берничә симфоник әсәр яза. «Башкорт биюләре», «Салават» исемле симфоник пьесасы, «Урал» кебек башкорт халык көйләренә нигезләнгән әсәрләре эре инструменталь формаларны үзләштерү юлында яңа адым, һәм башкорт халык көйләрен симфоник музыкага әвереледерүдә кыю тәҗрибәләр булалар. Күп кенә эпизодларында оркестровканың образлылыгы, милли колоритның оста бирелүе белән алар аерылып торалар. Соңга табарак та Ключарев башкорт халык иҗатына мөрәҗәгать итә һәм башкорт совет музыкасын үстерүдә әһәмиятле әсәрләр тудыра.

1937 елны Ключарев Казанга килә. Һәм шул елдан алып аның Татарстан музыка культурасын үстерү белән тыгыз бәйләнгән күп төрле хезмәтләре һәм иҗат эшчәнлеге башланып китә. ТАССР Министрлар Советы каршындагы элекке сәнгать эшләре идарәсенең музыкаль фольклор кабинетында эшләп, ул халык көйләрен җыючы экспедицияләргә җитәкчелек итә һәм бик күп районнарда йөреп йөзләгән халык көйләрен язып алып кайта.

1941 елны татар халык көйләре җыентыгы чыга. Бу фольклор кабинетының әһәмиятле зур эше була. Бу җыентыкны төзү һәм редакцияләү эшен Ключарев башкара. Музыкаль материалларны җыешуда шулай ук В. И. Виноградов белән шагыйрь М. Садрый да катнашалар.

Ключарев башкаручылар алдында торган бурычларны истә тотып иҗат итә. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле оешкан көннән алып, ул бу яшь коллектив өчен күп кенә әсәрләр тудыра. Ключарев халык моңнарының милли үзенчәлеген саклап, югары художестволы итеп, хор өчен көйләр эшкәртә. («Әллүки», «Кара урман», «Агыйдел» һ. б.). Болар беренче татар операсы хорлары белән бергә Татарстанның яшь хор культурасы үсешенә дә уңай йогынты ясыйлар.

Табигате белән бер тавышлы татар халык көйләрен хор өчен эшкәртү принципиаль әһәмияткә, идея-художестволы әһәмияткә ия иде. Татар халык көйләрен күп тавышлы итеп эшкәртү җыр культурасын үстерергә, аны баетырга зур мөмкинлекләр булдыра һәм башка халыкларның, бигрәк тә бөек рус халкының күп тавышлы җыр сәнгате белән ныклы бәйләнешкә керергә ярдәм итә.

Бөек Ватан сугышы елларында Александр Сергеевич Ключарев зур активлык белән музыкаль фольклор җыю

эшен дәвам итә, Ватан сугышы турындагы бик күп кенә татар халык көйләрен җыеп эшкәртә.

Сугыш елларында язган патриотик җырлары, шулай ук симфоник оркестр өчен икенче сюитасы халыкның мәхәббәтен казанды. Туган илнең мәһабәтлеген, Иделнең гүзәллеген мактаган халык көе «Су буйлап» сюитаның нигезенә салынган. Беренче кисәкнең көе кырыс, җитди яңгырый. «Скерцо» (икенче кисәк) — икенче характерда. Биредә яшьлек дәрте, ялкынлы хисләр белән сугарылган шатлыклы музыка. Скерцо сюитаның финалын — җиңүле маршны әзерли.

Сугыштан соңгы елларда да Ключарев актив иҗат итә. Дәртле, ялкынлы яшьләр җырларын һәм шулай ук җылы хисле лирик җырлар яза: «Мәңгелек яшьлек», «Бәхет җыры» (М. Садрый сүзләре), «Җыр яңгырый» (Ә. Фәйзи сүзләре), «Иртәнге җыр» (Ә. Ерикәй сүзләре) һ. б.

Эстрада әсәрләре тудыру өстендә дә Ключарев актив эшли. Фортепиано өчен («Шүрәле», «Этюд»), кларнет, гобой, баян, халык инструментлары оркестры өчен, тынлы оркестр өчен (комсомолның 30 еллыгына багышланган марш) әсәрләр яза.

1950 елны композитор зур хезмәтен — «Тау әкияте» балетын тәмамлый. Бу зур күләмле музыкаль сәхнә әсәре композиторның, һичшиксез, югары художестволы кыйммәткә ия булган хезмәте.

Балетның сюжет нигезендә Урал әкияте ята. Әкият җир асты байлыклары эзләүче башкортларның патша самодержавиесенә һәм җирле изүчеләр — тарханнарга каршы көрәшүе турында сөйли. Рус эшчесе Фрол җитәкчелегендә башкортлар баш күтәрәләр һәм үзләрен җәберләп торучы тарханны юк итәләр.

Тормышның, көнкүрешнең реаль картиналары белән, башкортларның героик көрәшләрен сурәтләгән күренешләр белән беррәттән, балетта әкият-фантастика белән бирелгән күренешләр дә зур урын алып тора. Мондый күренешләр җир асты байлыкларына хуҗа булган көч — Магдан образы белән бәйләнештә биреләләр. Магдан баш күтәрүчеләргә үзенең җир асты байлыкларын ачып ярдәм итә.

Балетта халык вәкилләре образын тудырырга омтылып композитор башкорт халык көйләрендәге, башкорт биюләрендәге интонацияләр, ритмнардан бик нык файдалана

һәм ышандырырлык массовый картиналар, халык вәкилләренең реаль образларын тудыра. Карт мастер Кыдрас, батыр йөрәкле Тимергол, аның сөйгән кызы Зарифалар үзләренең музыкаль характеристикалары аша җанлы портретлар булып күз алдына килеп басалар.

Балетның фантастик күренешләре дә музыкаль яңгырашлары ягыннан югары художестволы. Бигрәк тә Магдан образы аерылып тора. Шулай ук тау еланы белән булган көрәш тә бай фантазия белән иҗат ителгән.

Башкорт халык иҗатыннан оста файдаланып, композитор «Тау әкияте» балетын язганда, классик балетлар традицияләрен үзенә иҗат үрнәге итеп куя. Бу бигрәк тә төп теманы (көрәш темасы), төп образларны (бер-берсен сөюче Зарифа белән Тимергол) үстерүдә, симфонияләштерүдә күренә. Биредә автор совет балетларының уңышларыннан да (бигрәк тә Прокофьев балетларыннан) оста, иҗади файдалана.

Композицион яктан кайбер аерым кимчелекләре булса да (Фрол образының схематик булуы, музыкаль номерларның таркаулыгы) балетның музыкасы, тулаем алганда, образлы, матур яңгырашлы. Бу әсәрдә композиторның балет жанрын тирән аңлап, симфоник оркестр алымнарын белеп иҗат иткәнен күрсәткән күп кенә күренешләр, матур мелодияләр, гармоник табышлар бар.

«Тау әкияте» балеты 1951 елда Башкорт дәүләт опера һәм балет театрында куелып, тамашачының мәхәббәтен казанды. Балетның икенче симфоник сюита булып еш кына радио аша тапшырылган һәм концертларда башкарылган музыкасы киң популярлашты (икенче сюитаның партитурасы 1955 елда Музгизда басылып та чыкты).

Төрле жанрларда актив иҗат итү белән бергә, композитор Ключарев татар музыкаль фольклорын җыеп эшкәртүгә дә элеккечә һаман зур игътибар бирә. Аның бу өлкәдә күп еллык хезмәтенең җимеше булып 1956 елны зур китап — 250 көй тупланган җыентык, татар халык көйләренең икенче китабы чыкты. Бу җыентыкларның музыкаль-этнографик кына түгел, зур практик әһәмияте дә бар. Бу китапларга тупланган материаллардан композиторлар, артистлар, музыка белгечләре, үзешчән сәнгать коллективлары файдаланалар.

Ключарев Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле өчен элеккечә күп яза. Ул эшкәрткән хәзерге заман татар халык көйләре ансамбль башкаруында искиткеч халыкчан

яңгырыйлар. Мәсәлән: «Гармонь, гармонь», «Яшьлек җыры», «Колхоз бәйрәме», «Туган ил» һ. б. көйләр ансамбль репертуарында озак гомерле әсәрләр.

Композиторның соңгы елларда язган массовый җырлары да игътибарга лаеклы. Аның чын талантын күрсәткән дәртле, ялкынлы яки сагышлы лирик җырлары һәрвакыт табигый яңгырыйлар. Алар халык иҗатында булган интонацияләргә бик якын торалар, шуңа күрә тиз хәтердә дә калалар.

Якты лирика, табигать күренешләренә, туган илгә тирән мәхәббәт белән сугарылган «Идел дулкыннары» (М. Хөсәен сүзләре), «Яз җыры» (М. Садрый сүзләре), «Синең хакта», «Идел турында җыр» (Ә. Ерикәй сүзләре) һәм балалар өчен язган «Безнең дусларыбыз» (М. Хөсәен сүзләре) тиз арада киң таралдылар *.

Ключарев соңгы елларда зур күләмле инструменталь әсәрләр язуга күбрәк игътибар бирә. 1955 елда ул үзенең беренче симфониясен тәмамлады. Инструменталь музыка иҗат итү өлкәсендәге бөтен элекке тәҗрибәләре аңа симфония кебек зур күләмдә әсәр язуга әзерлек булды. Сюиталарында аның кискен характерлы күренешләрне һәм эпизодларны контраст кую күбрәк булса, симфонияләрендә драматик образларны бердәм симфоник үсештә ачуга омтылыш бар. Бу симфониянең үзәк темасы — киң Идел. Мәһабәт Идел — элекке Россия халыкларының азатлык өчен көрәше, совет халыкларының бердәмлеге, дуслыгы символы.

Симфониянең беренче кисәге лирик-эпик характердагы киң сулышлы кереш белән башланып китә. Бу кисәкнең төп бүлегендә музыка динамик-киеренке үсеш белән бара һәм чын драматизмның кульминацион ноктасына җитә.

Икенче кисәк һәлак булган геройлар истәлегенә багышланган. Бу кисәкнең музыкасы уйчан, сагышлы.

Өченче кисәк көнкүреш картиналарын сурәтли. Биредә композитор берничә халык көен файдалана.

Дүртенче кисәк — финал — халык бәйрәме, тантана. Бу кисәкнең урта өлешендә Ключаревның танылган «Яз җыры» көе яңгырап үтә. Финал керештәге кебек киң ко-

---

* «Идел дулкыннары», «Яз җыры», «Безнең дусларыбыз» 1953 елда Татарстан культура министрлыгы тарафыннан үткәрелгән конкурста премиягә лаеклы булдылар.

лачлы көй белән, мәһабәт рус елгасының көчле образын гәүдәләндерүче музыка белән тәмамлана.

Симфониянең аерым кисәкләрендә музыка художестволы, образлы яңгыраашта иҗат ителгән булса да (бигрәк тә беренче кисәктә), композиторның бу симфониясе аша бирергә теләгән тирән фикере әле тулысынча ачылып җитмәгән. Үзәк симфоник үсеш зәгыйфьрәк булганга, аерым кисәкләрнең эчке бердәмлеге туып җитмәгән.

А. С. Ключарев бу әсәрен тәмамлагач, симфоник оркестр өчен бишенче сюитасын яза. Бишенче симфоник сюитасын ул инде башкорт халык көйләренә нигезли. Бу юлы инде композитор симфония язгандагы кебек үзалдына зур бурычлар куймый, бу әсәр симфоник эпизодлар характерындарак. Шулай да музыкаль образлар аша башкорт халкы тормышыннан аерым күренешләр, туган ил табигатенең гүзәллеге күз алдына килеп баса.

Беренче кисәкнең нигезендә — андантеда — башкорт халкының матур табигатьле Урта Азия җирләренә мәхәббәте турындагы «Сыр-Дәрья» дигән көе ята.

Икенче кисәк — андантино. Башкорт халкының борынгы көе «Артылын» бирелә киң һәм иркен сулыш белән агыла. Бу кисәктә халык туган ягының сөекле табигатен мактап җырлый.

Өченче кисәк — аллегро виво. Бу — яшьләрнең күңел ачуы, бию күренеше. Бу кисәкнең музыкасында башкорт халкының хәзерге заман такмакларындагы интонацияләр ишетелә. Композиторның халык көйләрен эшкәртүдәге бай иҗат фантазиясе, уйлап табучанлыгы бу сюитада тагы бер тапкыр күренә.

Бу сюита 1955 елда Москвада үткәрелгән башкорт сәнгате декадасы концертларында башкарылып, зур уңыш казанды.

Хәзерге вакытта А. С. Ключарев «Русский характер» исемле опера өстендә эшли. (А. Толстойның шул исемдәге әсәреннән Ю. Каменецкий либреттосы.)

Композитор Ключарев музыка өлкәсендәге җәмәгать эшләренә дә актив катнаша. Ул үзешчән композиторлар белән очраша, аларга иҗади ярдәм итә, үзешчән сәнгать коллективларына булыша. Радиокомитетта һәм үзәк звукозапись йортында үткәрелгән татар музыкасын пленкага язып алуда Ключарев күп еллар буе художество җитәкчесе. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленә, Халык иҗаты йортында үзешчән сәнгать коллективларына өзлексез

ярдәме композиторның игътибарлы музыка эшлеклесе булуын күрсәтә. Татарстан совет композиторлары союзы оешкан көннән алып, Ключарев оештыру комитеты члены һәм правление члены булып тора.

Татар музыка культурасын үстерү эшендә күренекле хезмәтләре өчен А. С. Ключаревка 1939 елны Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде.

1956 елның язында Татарстан республикасы җәмәгатьчелеге Александр Сергеевич Ключаревның тууына 50, иҗат эшчәнлегенә 30 ел тулуны билгеләп үтте. Илле еллыгын композитор тулы иҗат көчендә, музыкаль эшчәнлегенең чәчәк аткан чагында каршылады. Җәмәгатьчелек аның татар музыка культурасын үстерүдәге зур хезмәтләрен лаеклы рәвештә бәяләп, билгеләп үтте.

Татар музыка сәнгатен үстерүдәге күренекле хезмәтләре өчен һәм Москва шәһәрендә татар сәнгате һәм әдәбияты декадасы уңае белән Александр Сергеевич Ключарев Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде.